ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.03.2022 г. Заинск № 153

**«Гражданнарны аз керемле дип тану максатларында керемнең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында»**

Гражданнарны азкеремле дип тану һәм аларга муниципаль торак фондындагы торак урыннарны социаль наем шартнамәләре буенча бирү максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексының 49 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гражданны аз керемле дип тану максатларында гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен расларга. (Кушымта.)
2. «Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында керемнең һәм мөлкәт бәясенең чик күрсәткечләрен билгеләү турында» 2021 елның 26 мартыннан 188 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Уртак торак-көнкүреш комиссиясенә гражданнарны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ дип таныганда кушымтада күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.
4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
Юрист

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 28 март
153 номерлы карарына
кушымта

**Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаилә әгъзаларының һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының чик күрсәткече**

| Гаилә әгъзаларының саны | Гражданны аз керемле дип тану максатларында гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының чик күрсәткече (сум) | Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең чик күрсәткече күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1 | 1 218323,70 | 27670,85 |
| 2 | 1 550593,80 | 17608,71 |
| 3 | 1 993620,60 | 15093,18 |
| 4 | 2 658160,80 | 15093,18 |
| 5 | 3 322701,00 | 15093,18 |
| 6 | 3 987241,20 | 15093,18 |
| 7 | 4 651781,40 | 15093,18 |
| 8 | 5 316321,60 | 15093,18 |
| 9 | 5 980861,80 | 15093,18 |
| 10 | 6 645402,00 | 15093,18 |

Башкарма комитетның
эшләр идарәчесе Т.А.Лоптова